**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында контракт буенча хәрби хезмәт узучы гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында

«Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарга ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм**:

1. Контракт буенча хәрби хезмәт узучы һәм контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пункты (1 разрядлы), Казан шәһәре, яисә Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты тарафыннан «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» исемле батальоннарга юлланган гражданнарга социаль ярдәм чарасы буларак 360 000 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2022 елның 23 июнендәге ПУ-438 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» Указына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 13 августындагы ПУ-557 номерлы Указы.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 08 май
№ 325